КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 30 март г.Казань № б-711

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 июнь, б-1214 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, б-2273 нче; 2022 ел, 26 май, б-1061 нче; 2023 ел, 9 июнь, б-1311 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Ел саен үткәрелә торган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составын яңа редакциядә (боерыкка теркәлә) бәян итәргә;

әлеге боерык белән расланган Ел саен үткәрелә торган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасын әзерләү һәм уздыру турындагы нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

4.3.3 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финалның сигездән бер өлешенең парлар составы әлеге Тәртипнең 1.2 нче кушымтасы буенча спортның уен төрләре буенча ярышлар уздыру регламенты нигезендә билгеләнә.»;

4.3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.4. Җиңел атлетика.

Ярышларның характеры – команда характерында.

Команда составы – 4 кеше, шул исәптән 2 ир-ат һәм 2 хатын-кыз.

Ярышлар 100ешәр метрдан 4 эстафета рәвешендә уздырыла.

Эстафетада йөгерү тәртибе: 1 нче һәм 2 нче этапларда – хатын-кызлар, 3 нче һәм 4 нче этапларда – ир-атлар.

Урыннар команданың эстафетаны узу вакыты буенча билгеләнә.»;

4.3.6 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финалның сигездән бер өлешенең парлар составы әлеге Тәртипнең 1.2 нче кушымтасы буенча спортның уен төрләре буенча ярышлар уздыру регламенты нигезендә билгеләнә.»;

4.3.9 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финалның сигездән бер өлешенең парлар составы әлеге Тәртипнең 1.2 нче кушымтасы буенча спортның уен төрләре буенча ярышлар уздыру регламенты нигезендә билгеләнә.»;

Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре спартакиадасын уздыру тәртибенә 1.2 нче кушымтаны яңа редакциядә (боерыкка теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 27 июнь, б-1214 нче
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 март, б-711 нче
боерыгы редакциясендә)

Ел саен үткәрелә торган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры, оештыру комитеты рәисе |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары –Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Вострикова Светлана Анатольевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Зарипов Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Мищихин Александр Васильевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Прокофьева Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Садриев Илдар Зөфәр улы | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары |
| Семенова Вера Сергеевна | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары. |

______________________________

Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре спартакиадасын уздыру тәртибенә 1.2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 март, б-711 нче
боерыгы редакциясендә)

Спортның уен төрләре буенча ярышлар уздыру
регламенты

Баскетбол, мини-футбол һәм волейбол

1 нче этап: командалар рейтинг буенча (узган елның Спартакиадасы кысаларында әлеге спорт төре нәтиҗәләре буенча) 8 төркемгә (шобага салып) бүленә – A, B, C, D, E, F, G, H.

Төркемнәрдәге уеннар бөҗра система буенча – һәрберсе бер-берсе белән.

Финалның сигездән бер өлешенә һәр төркемнән ике команда чыга. Ике һәм аннан күбрәк командаларның очколары тигез булганда, командаларның төркемдәге урыннары түбәндәге өстәмә күрсәткечләр буенча билгеләнә:

1) үзара уеннар нәтиҗәсе (очколар, туплар, голлар аермасы);
2) тупларның гомуми аермасы;
3) барлык уеннарда кертелгән туплар саны;
4) шобага салу.

2 нче этап:

Финалның сигездән бер өлеше – парларның составы түбәндәге формула буенча төркем этабы уеннарын үткәрү йомгакларыннан чыгып билгеләнә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| [ 1 ]:<br>A1 – B2 | [ 2 ]:<br>B1 – A2 | [ 3 ]:<br>C1 – D2 | [ 4 ]:<br>D1 – C2 | [ 5 ]:<br>E1 – F2 | [ 6 ]:<br>F1 – E2 | [ 7 ]:<br>G1 – H2 | [ 8 ]:<br>H1 – G2 |

финалның дүрттән бер өлеше:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «A»:<br>җиңүче[1][ 1 ] –<br>җиңүче [ 2 ] | «B»:<br>җиңүче [ 3 ] –<br>җиңүче [ 4 ] | «C»:<br>җиңүче [ 5 ] –<br>җиңүче [ 6 ] | «D»:<br>җиңүче [ 7 ] –<br>җиңүче [ 8 ] |

финалның икедән бер өлеше: җиңүче «A» – җиңүче «B»; җиңүче «C» – җиңүче «D»;

3 – 4 нче урыннар өчен матч;

финал.

[1]җиңүче – җиңүче команда.

Өстәл теннисы һәм бадминтон

1 нче этап: командалар рейтинг буенча (узган елның Спартакиадасы кысаларында әлеге спорт төре нәтиҗәләре буенча) 8 төркемгә (шобага салуып) бүленә.

Төркемнәрдәге уеннар божра система буенча – һәрберсе бер-берсе белән.

Финалның сигездән бер өлешенә һәр төркемнән ике команда чыга. Ике һәм аннан күбрәк командаларның очколары тигез булганда, командаларның төркемдәге урыннары түбәндәге өстәмә күрсәткечләр буенча билгеләнә:

1) үзара уеннар нәтиҗәсе (очколар, партияләрдә, геймаларда очколар аермасы);
2) партияләрдә, геймаларда очколарның гомуми аермасы;
3) шобага салу.

2 нче этап:

Финалның сигедән бер өлеше – төркем этабы уеннары үткәрелгәннән соң шобага салу йомгаклары буенча билгеләнә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| [ 1 ] | [ 2 ] | [ 3 ] | [ 4 ] | [ 5 ] | [ 6 ] | [ 7 ] | [ 8 ] |

финалның дүрттән бер өлеше

| «A» | «B» | «C» | «D» |
|---|---|---|---|
| җиңүче [ 1 ] җиңүче [ 2 ] | җиңүче [ 3 ] җиңүче [ 4 ] | җиңүче [ 5 ] җиңүче [ 6 ] | җиңүче [ 7 ] җиңүче [ 8 ] |

финалның сигездән бер өлешендә оттырганнар өчен сетка

| «E» | «F» | «G» | «H» |
|---|---|---|---|
| отт[2] [ 1 ] отт [ 2 ] | отт [ 3 ] отт [ 4 ] | отт [ 5 ] отт [ 6 ] | отт [ 7 ] отт [ 8 ] |

5 – 8 нче урыннар өчен турнир сеткасы
(1) отт «A» – отт «B»
(2) отт «C» – отт «D»

7 – 8 нче урыннар өчен матч
отт (1) – отт (2)

5 – 6 нчы урыннар өчен матч
җиңүче (1) – җиңүче (2)

финалның икедән бер өлеше
(5) җиңүче «A» – җиңүче «B»
(6) җиңүче «C» – җиңүче «D»

3 – 4 нче урыннар өчен матч
отт (5) – отт (6)

13 – 16 нчы урын өчен турнир сеткасы
(3) отт «E» – отт «F»
(4) отт «G» – отт «H»

15 – 16 нчы урыннар өчен матч
отт (3) – отт (4)

13 – 14 нче урыннар өчен матч
җиңүче (3) – җиңүче (4)

9 – 12 урыннар өчен турнир сеткасы
(7) җиңүче «E» – җиңүче «F»
(8) җиңүче «G» – җиңүче «H»

11 – 12 нче урыннар өчен матч
отт (7) – отт (8)

[2]отт – оттырган команда.

финал
җиңүче (5) – җиңүче (6)

9 – 10 нчы урыннар өчен матч
җиңүче (7) – җиңүче (8).

___